ФАЙДАЛЫ БУЛСЫН!

Белгечләр әти-әниләрнең балалар ризыгына игътибар бирмәве турында кисәтә

> 2

ШИФА ЭЗЛӘП

«ВТ» хәбәрчесе хастаханәдә чират торып кайтты

> 2

МАННУР АБЫЙ

Танылган язучының күпләр белмәгән тормыш сәхифәләре

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 17 (28790) | Шимбә | 5 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

КҮРШЕҢ ТҮЛӘРМЕ?

БИРӘСЕ БАР ОНЫТЫР, АЛАСЫ БАР ОНЫТМАС

Ел башына Татарстанда яшәүчеләрнең торак-коммуналь хезмәтләргә бурычы 8 миллиард сумга җиткән. Бу хакта Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин хәбәр итте. Түләмәүчеләр – кемнәр алар? «ВТ» журналисты әнә шул сорауга җавап эзләде.

Күп очракта бурычларны түләтер өчен әҗәтлеләрнең утын өзү, суын туктату, канализациясен ябып куюу кебек чаралар күрелә. Пандемия аркасында бу катгый чаралар тукталып торды. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүче оешмалар халыкның хәленә керергә тырышты. Кем түли, кем түләми, яшереп калмыйлар хәзер: бурычлылар турындагы барлык мәгълүматны подъездларда «милекчеләр почмагы»на урнаштырып баралар. Казанның Совет районындагы Фәйзи, Глушко, Ваһапов урамнарында исә бурычлы кешенең исем-фамилиясе, ничә сум әҗәте барлыгы йорт диварына язылып куела. 20 елдан артык Азинода яшәүче Фатыйма Мусина, кеше өчен түләп арыдык инде, ди.

– Күршемдә бер эчкече ир яши. Кеше җыеп ятарга ярата. Пенсиясен ала да эчеп бетерә. Әҗәте күп җыелган инде. Берничә йөз меңгә җиткән. Андыйлар кер дә юмый, үзе дә юынмый, чүп тә ташламый бит инде. Бер карасаң, бурычы да әллә ни җыелмас төсле. Тик тәртип бер: фатирда яшисең икән, түлисе, – ди Фатыйма апа. – Мөгаен, күршем коммуналь хезмәтләр өчен исәпләгеч буенча түләмидер дә. Матур гына йөргән чагында, әкрен генә әйтәм, аңлатам да инде. Тик файда юк. Эше судта икән инде. Фатирыннан чыгарып, урамда калмаса ярый.

«Жилище и комфорт» идарәче оешмасы вәкилләре иң элек әҗәтлеләр белән яхшы мөгамәлә булдырырга тырыша икән. Ничек тә, уртак тел табып, бурычны түләтмәкчеләр.

– Түләү-түләмәү кешенең үзеннән тора. Әҗәтлеләрне начар яши димәс идем мин. Дөрес, арада ирсез калган, әлегә түли алмыйм, диючеләр дә бар. Әмма андыйлар ике айдан артык бурыч җыймый. Ә кайбер кеше махсус түләми. Бер йортның тапшырылганына 12 ел инде. Шул вакыт эчендә бер дә түләмәгән кешеләр бар. Өйләренә кисәтү кәгазе алып килгәндә, түлибез, дип калалар, әмма әйткәнне үтәмиләр, – ди идарәче оешма хезмәткәре Тамара Ильина. – Без хезмәт күрсәткән йортларның кайберендә бурычлы бер генә кеше дә булмый. Ә кайсыларында 2–3 кеше түләми. Кемдер, кредитым күп, ди, икенчеләр оешмага ачулы, өченчеләр акча җиткезә алмауга сылтый.

Тамара ханым сүзләренчә, алар көн саен диярлек бурычлыларны эзләп йөри. Өйдә чакларын туры китерер өчен, хезмәткәрләргә атналар буе бер адреска килергә туры килә. Әмма алты ай түләмәсәләр, алар белән оешма юристлары эшли башлый икән. Ахыр чиктә, эш судка ук барып җитә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘРГӘ ТҮЛӘҮНЕ КИМЕТҮ ӨЧЕН:
- фатирларга шәхси исәпләгечләр урнаштырырга кирәк;
- кайнар, салкын су, электр энергиясе һәм газга исәпләгеч куеп була. Бу очракта күпме тотасыз, шуны гына түләячәксез;
- электр энергиясен аз тоту өчен сакчыл лампочкалар куйдырыгыз;
- көнкүреш җиһазларының «А» классын сайлагыз;
- су краннарын экономияле режимга көйләгез;
- бәдрәфтәге суны күп сарыф итмәс өчен, махсус җайланма урнаштырыгыз;
- өегездәге һәр торба, кран төзек булсын.

«Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры Дмитрий Романов коммуналь хезмәтләр өчен түләмәүчеләрне берничә төркемгә бүлә.

– Беренчесе – төгәллек яратмаучы кешеләр. Андыйларның акчасы да бар, әмма алар бу эшне сузып йөри, вакытында түләми. Бурычы җыелгач кына, аны каплый башлый. Икенче төркемгә җәмгыятьтән читләшеп, төрле бәйлелектән интегүче кешеләр керә. Бурычлылар арасында аз керемле кешеләр, акчасын җиткерә алмаучы пенсионерлар да бар. Әмма соңгылары бик тәртипле. Мөмкинлек булуга, әҗәтләрен түлиләр, – ди Дмитрий Романов.

Идарәче оешманың эшчәнлегеннән канәгать булмаган кешеләр дә, кимчелекләрне бетергәч, бурычын түли икән. Арада кайбер түләүләрне чигереп, анысын түләмәскә дә була, дигән сүз ишетеп, бурыч җыючылар да бар. Дмитрий Романов шулай ди.

– Ике айдан артык коммуналь хезмәтләр өчен түләмисең икән, бурыч суммасы шактый җыела. Арада үзенә субсидия тиешлеген белмәүчеләр дә очрый. Шуңа да хезмәт ветераны, эшкә яраксыз кеше, аз керемле һәм күпбалалы гаиләләр үзләре яшәгән районның социаль яклау бүлегенә барып, үзләренә тиешле ташлама яки субсидияне рәсмиләштерә ала, – ди ул. – Әгәр кешенең хәле авыр, вакытлыча түли алмый икән, бу очракта идарәче оешмага барып, бурычны түләргә вакыт бирүләрен сорап, гариза язарга кирәк. Ә инде үзегезгә хезмәт күрсәтүче оешма начар эшли, кайбер хезмәтләрне җиренә җиткермичә башкара икән, иң элек кулыгызда шуны дәлилләгән документ булсын. Моның өчен оешмага барып, бар кимчелекләрне күрсәтеп, акт төзергә кирәк. Бары тик шул очракта гына фатир өчен түләүне яңадан исәпләтеп алырга мөмкинсез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Яңа фонд барлыкка килде

Татарстанда җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү буенча «Игелек-Доброта» республика фонды гамәлгә куелды. Президент Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән тиешле Указны имзалады. Күзәтчелек советына да Президент үзе җитәкчелек итәчәк. Аның урынбасарлары – Президент Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров һәм Министрлар Кабинеты аппараты башлыгы Шамил Гаффаров. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов Попечительләр советы рәисе булачак.

Фонд, җәмгыятьне рухи-әхлакый яктан үстерү белән беррәттән, Татарстан халыкларының гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклау, шулай ук фәнни, мәдәни, интеллектуаль, туристлык мөмкинлекләрен үстерү өчен дә булдырыла. Гамәлгә куючысы – Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы. Фонд Казанда республика бюджеты хисабына эшләячәк.

Дәвалау өчен миллиардлар

2021 елда Татарстанда онкологик чирләре булган сырхауларны ачыклау күрсәткече арткан. Шулай итеп, 100 мең кешегә 430 очрак туры килә. Үлем-китем күрсәткече 6 процентка (100 мең кешегә – 175,4) кимегән. Әлеге мәгълүмат белән «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында уртаклаштылар.

Яман шеш белән авыручыларны I һәм II стадиядә үк ачыклау күрсәткече 61,7 процентны тәшкил иткән. Димәк, авыруны алданрак дәвалау мөмкинлеге дә арткан.

Узган елның тагын бер яңалыгы – Чаллы һәм Әлмәттәге республиканың онкология үзәге филиаллары базасында сырхауларга радиотерапевтия ярдәмен күрсәтү. Аннан 917 кеше файдаланган. Сырхаулар моннан файдалану өчен элек Казанга килергә мәҗбүр иде.

Гомумән алганда, былтыр Татарстанда яман шеш авыруларын дәвалау өчен 3 млрд сумнан артыграк күләмдә акча бүлеп бирелгән. Матди ярдәм кыйммәтле аппаратура сатып алу һәм башка хезмәтләр өчен тотылган.

Узган айныкын да алалар

Эшләмәүче пенсионерлар, 8,6 процентка арттырылган пенсия белән бергә, узган айда биреп бетерелмәгән өстәмәне (8,6 процент белән 5,9 процент арасындагы аерма турында сүз) дә ала башлаган. Бу хакта Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте хәбәр итә.

Бүлек идарәчесе Эдуард Вафин аңлатып үткәнчә, өстәмә күләме төрле кешенең төрлечә, чөнки ул пенсия күләменә бәйле. Аның өчен Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәкми – автомат рәвештә түләнелә. Шулай итеп, Татарстанда бер миллионнан артыграк эшләмәүче пенсионерның пенсиясе 8,6 процентка арттырылган. 2021 елдагы инфляция (8,4 процент) белән чагыштырганда, зуррак күрсәткеч бу.

COVID-19

Ай үсәсен көн үсә

Медицина тармагы эшендә дә, җәмгыятьтә дә киеренкелек саклана. 2022 елның беренче атнасыннан башланган коронавирус белән авыручылар саны арту дәвам итә. Сораулар да кимеми. Гадәттәгечә, атна азагында аларга Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Роспотребнадзор идарәсе белгечләре җавап бирә.

1. Вазгыять ни хәлдә?

Узган тәүлектә республикада COVID-19 йоктыручылар саны 996 кешегә җиткән. Гыйнвар аенда авыручылар саны, 2021 елның декабрендә авыручылар саны белән чагыштырганда, 32,6 процентка арткан. Элеккечә үк гаилә эчендә авыручылар саны, хезмәт коллективларында чирләүчеләргә караганда, 4,4 мәртәбә күбрәк. 2022 елның беренче атнасыннан ук авыручыларның артуын күзәттек һәм бу дәвам итә. Әйтик, беренче атнада – 8, аннан – 15, өченче атнада 74 процентка «үстек». Узган атнада бу күрсәткеч 2,8 тапкыр артты.

Чиргә бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын үтәүне тикшерү юнәлешендә эш бара. Бер атна эчендә Роспотребнадзор хезмәткәрләре 305 объектны тикшерде. Барлыгы 144 беркетмә төзелде, бер кафе эшен туктатты.

Республикада 56 йогышлы авыруларның вакытлыча госпитале эшли. Коронавируслы сырхаулар өчен 4057 ятак каралган. Шуларның 13,6 проценты гына буш, 3508 ятакта – сырхаулар. Гомумән алганда, урыннарга бәйле проблема күрмибез. Кирәк очракта, ятаклар санын арттыру мөмкин.

Моңа өстәп республикада грипп сезоны да дәвам итә. Чирләүчеләр эпидемиологик чиктән ике мәртәбә артыграк. Республикада 867 очрак теркәлде. Тик бу шушы чор өчен хас. Сезон әле мартка кадәр дәвам итәчәк.

2. Вакцина ясатучылар күпме?

Коронавируска каршы вакцинаның беренче дозасын республика халкының 79,1 проценты, ягъни 2409864, икенчесен 1891236 кеше алган. Ревакцинацияне 199 мең кеше узган. Әмма бу сан күбрәк булырга тиеш, чөнки ярты ел элек 620645 кеше вакцинация узган иде. Барлыгы 701 балага вакцина ясадылар.

3. Чикләү чараларын бетерү яисә өстәмәләрен кертү турында сүз юкмы?

Татарстан территориясендә гамәлдә булган барлык чикләү чаралары калачак, QR-код системасын бетерү турында да сүз юк. Өстәмә чаралар кертү мәсьәләсе каралмый.

4. Планлы медицина ярдәме кабат кайчан күрсәтелә башлый?

Планлы медицина ярдәмен күрсәтү сырхауханәләрдә генә туктатылды. Стационарларда ярдәм күрсәтү дәвам итә. Планлы операцияләр дә үз вакытында ясала.

Планлы медицина ярдәме кемнәр өчен гамәлдә булуын искәртеп үтик. Болар – әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыручы авырулары (гепатит, туберкулез, шикәр чире һ.б.) булган сырхаулар, йөкле хатын-кызлар, билгеле бер вакытка медицина ярдәмен күрсәтүне кичектереп тору ярамаган чирлеләр, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле һәм килешү нигезендә хезмәт итүче затлар.

Билгеле, без дә тизрәк бу дулкынның тынуын телибез. Шундук барысына да планлы медицина ярдәмен күрсәтүгә кире кайтачакбыз.

Сүзгә-сүз

Гөлнара ГАБДРАХМАНОВА, Татарстанның архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе:

Хәзерге мәктәп балаларының да, ата-аналарының да идеологиясе юк. Алар нишләгәннәрен үзләре дә белми. Без зыялырак балалар идек, ничек тә яхшы белем алырга тырыштык. Гәрчә безнең мөмкинлекләребез хәзергегә караганда күпкә азрак иде. Совет чоры баласы бары тик үзенең белеменә генә таяна алды.

(«Татарстан» журналыннан)

РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ АКЧАГА МӨНӘСӘБӘТЕ

Коронавирус китергән кыенлыкларга карамастан, россиялеләрнең күпчелеге акча тоту рәвешен үзгәртмәгән. Алар кыйммәтле әйберләр сатып алудан баш тартырга җыенмый. Дүрт кешенең берсе генә киләчәк өчен мая туплаганын әйткән. «Райффайзенбанк» оештырган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә.

Коронавирус финанс гадәтләрне үзгәрттеме?

акчага сак карыйм	25 %
финанс гадәтләрем үзгәрмәде	61 %

Көтелмәгән чыгымнар өчен дигән акча кайда саклана?

банкта	13 %
өйдә	30 %

Кәгазьгә эш кими

14 февральдән Күпфункцияле үзәкләрнең барлык филиалларында 108 хезмәт электрон рәвештә күрсәтелә башлый. Күпфункцияле үзәк директоры Ленара Мозаффарова шулай дип белдерде. Бу эш сынау рәвешендә башкарылачак.

1 апрельдән исә кәгазь документлар бирү тулысынча туктатыла. Барлык документлар да электрон рәвештә генә булачак. Аның сүзләренә караганда, бу эш тәмам җайга салынгач, МФЦның цифрлы хезмәтләре 137гә җитәргә тиеш. Шул ук вакытта яңа төр хезмәтләр дә пәйда булачак. Нәтиҗәдә хезмәт күрсәтүче органнарның электрон документлар архивы булдырылачак, муниципаль хезмәтләр алу өчен документларны үз районында гына түгел, теләсә кайда тапшыру мөмкинлеге барлыкка киләчәк. Әйтик, Әлмәт башкарма комитеты хезмәтләрен Казан филиалында алырга мөмкин булачак.

tatarstan.ru

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Теле пычракның җаны чистамы?

Рәсми тел, әдәби тел, норматив тел булган кебек, урам теле дигән лөгать тә бар бит әле. Әдәби телдән күпкә ярлы, сүз запасы азрак булган сөйләм. Гади халык көнкүрештә үзара аралаша торган ул телне шартлы рәвештә икегә бүлеп карарга мөмкин кебек. Ярлы булса да, колакны ярган сүзләрдән азат телгә һәм тозлы, борычлы кәлимәләр кулланып сөйләшә торганга. Соңгы очрак, мәгълүм ки, норматив булмаган лексика, татарча әйткәндә, сүгенеп сөйләшү була инде. Бу атнаның пәнҗешәмбесе шундый сүзләргә каршы халыкара көрәш көне (Всемирный день борьбы с ненормативной лексикой) дип билгеләп үтелгәнгә, без дә әлеге темадан читтә калмаска булдык.

Япон телендә гомумән дә сүгенү сүзләре юк, дип укыган идем. Ул халыкны үзара бик итагатьле диләр бит – булыр да. Тик менә иң итагатьле кешенең дә ачуы кайнап чыккан вакытлар була ич. Ул чагында нишлисе? Имештер, япон футболчылары, ачулары чыкканда, берберсен яисә каршы як команда вәкилләрен, аптырагач, испан, португал, инглиз телендәге алама сүзләрне кулланып битәрли, шуларны сибә икән. Кыскасы, кем нинди телдә нинди «яхшы сүз» белә – шуны куллана. Татар урысча сүгенгән кебегрәк килеп чыга инде. Нәфрәтләнгәндә, кан кызганда әйтелә торган сүзләр, «авыртуны җиңеләйтә торган»нар һәр халыкта да бардыр инде ул. Японнар, үзләренә тугры калып, андый чакта бөҗәкләргә мөрәҗәгать итә икән. Мәсәлән, кайсыдыр халык җиде катлы итеп сүгенер чакта алар «сытылган кандала» яисә «эче чыккан таракан» ди дә бетерә. Әлбәттә инде, моның ишене сүгенүгә кертеп булмый. Тик кемдер сине «эче чыккан таракан» дип атаса, бер дә шәп түгел инде. Андый чакта җавапсыз калу авыр. Ярый ла бөҗәкләр белән генә чикләнеп калсаң...

Татар телендә дә «түгәрәк сүзләр» хәтсез. Тик, күрәмсең, барыбер бик үк җитәрлек түгел. Күпчелек урысча сүгенмәс иде андый дефицит, кытлык булмаса. Лингвистлар әйтүенчә, сүгенү кәлимәләренең төбендә һәркем дә белгән өч-дүрт тамыр сүз ята. Гади халык кирәкмәгәндә бик тә иҗади, креатив бит безнең – ул шул сүзләрне җитмеш җидегә боргалап, бөкләп, килешләргә салып, ярлы сөйләмен шәпләп «баета». Урыс телен гайрәтле дип, бәлки, сүгенү сүзләре күп булганга да атыйлардыр. Шунысы да бар: төрләндерүләр, гомумән, әшәке сүз куллану ызгыш, ачу, агрессия белән күпвакыт турыдан-туры бәйләнмәгән. Көн саен үтәлә торган ритуал – бер сәгатьлек кичке сәйранда фәкыйрегез ул үзенчәлеккә шактый еш тап була. Үсмерләр җыелган компанияләрдә – бакча-скверларда очрыйлар, тротуарларда йә мин аларны узып китәм, йә алар мине. Шул чакта колакның шәлперәеп шиңүләре...

Дүрт-биш кешелек төркемдә гадәттә берәр егет кисәге нидер сөйләп бара, калганнары тыңлый. Җөмлә саен ике-өч «ялгавыч» сүз. Күңелгә тигәне – өлкәннәрне «күрмәүдән» бигрәк, компаниядәге кызларның егет әйткән һәр сүзгә чыркылдап көлүе. Ул гынамы? Ике-өч үсмер кыз юкны-барны сөйләшеп каядыр ашыга һәм үзара әңгәмәдә без начарга, алар гадәтигә санаган сүзләрне рәхәтләнеп сибә. Ана булачак затлар. Мин үземне тынычландырган булам: «Гаиләдә адәм рәтле тәрбия алып үскәннәр бу вакытта дәреслек тотып утырадыр», «кыен» категориясенә эләккәннәр генә урамда бутала, күпчелек андый түгел», – дим. Туктап, «лекция» укыган вакытлар да булгалады. «Сүгенеп, җыен алкаш, бомж, башка адәм актыклары гына сөйләшә – үзеңне шулар белән янәшә куясың ич, кешечә сөйләшеп кара», – дия идем. Дәшми тыңлап торалар, килешкән дә сыман итәләр иде, тик... Бер-ике атнадан шулар ук очрый, сөйләшүләре элеккечә үк «бизәкле».

Яшүсмерләрдәге тилемсә менталитетны яшьлеккә, алардагы субкультурага сылтап аңлатырга була, әлбәттә. Алардагы кыланчыклык, кәттә, гаярь булып күренәсе килү, сүгенүгә һәвәслек шул менталитетның состав өлешләре. Яшьтәшләре алдында алар үз-үзләрен шундый күркәм булмаган юллар белән «күтәрә». Акыл кергәч, күбесе алай кыланмаячак. Яшьләрдә генә түгел, гомумән, норматив булмаган лексикага әле тагын «сленг», «жаргон» дип аталучы категориядәге сүзләрнең дә керүе мәгълүм. Тыелмаган, ләкин телне баетудан бигрәк аны чүпләүче сүзләр. Өлкәннәр дә бөтенләй үк баш тартмаган ул кәлимәләрне дә яшь-җилкенчәк бик тә теләп куллана. «Телка», «тачка», «чалить», «фиолетово», «прикид» – алар шактый күп. Сүгенүгә кермәгән ул сүзләр дә үсмерләргә башкалардан аерылып тору, кәттә буласы килүдә шәп ярдәмче санала. Татар телендә генә, белүемчә, «сленг» юк. Бу очракта да, безгә, теләсәк-теләмәсәк тә, урысчага мөрәҗәгать итәсе...

Яңадан сүзләрнең «тозлы»ларына кайтыйк. Аларның агрессия вакытында, ачу чыккан чакта әйтелгәннәренә. Без барыбыз да хәзер белемле халык, чамалыйбыз: сүзләрнең дә энергетикасы бар. Әле нинди генә энергетика. Сүз белән кешене дәваларга, терелтергә һәм, киресенчә, чирләтергә, хәтта ки үтерергә дә була, диләр. Теле пычракның эче чиста түгел. Ачу белән ярсып әйтелгән начар сүз – җимергеч энергетика, эчтәге шакшыны, кара энергияне шул сүзләргә төреп «эфир»га җибәрү, башкаларга күчерергә омтылу. Кешегә эләкмәгән тәкъдирдә дә җимергеч ул көч катлам-катлам булып әйләнә-тирәгә утыра, диләр. Күптән бер укыган идем, лабораториядә, бодай орлыкларын начар сүзләр белән «эшкәртеп», туфракка утыртканнар. Утырткач, аларга шундый ук катлы-катлы оятсыз сүз сеңдерелгән су сибеп торганнар. Нәтиҗәдә орлыкларның 49 проценты гына тишелеп чыккан. Шундый ук орлыкны догалар укып утырткач, шытым 98 процент тәшкил иткән. Сүгенүнең асылын, сүзнең матди булуын төгәл аңлаткан тәҗрибә бу.

Кеше дигәнең – үзенчәлекле зат. «Ул стрессны, ул ачуны эчемдә йөрткәнче, рәхәтләнеп катлы-катлы итеп сүгенәм дә тышка чыгарып ташлыйм, бушанып калам, котылам», – диючеләр бар. Юк шул менә, кара энергия ерак китми. Ул безнең тирә-ягыбызда, без яшәгән мохиттә кала. Торган йортта, фатирда, эш урынында, урамда, ишегалдында кара болыт булып асылынып тора, сулар һавабызны, эчкән суны, туфракны агулый. Шулар аша яңадан бәндәгә әйләнеп кайта. Күңелсезлек, хәвеф-хәтәр булып, чир булып. Кешеләр сүгенеп, карганып, кемнедер каһәрләп, яманлап йөрүдән туктаганда гына дөньябыз сафлана, борчулар кими, хасталар бетә алыр иде кебек.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров Казанда берничә предприятиенең эшчәнлеге белән танышты.

Иң элек Денис Мантуров Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Горбунов исемендәге Казан авиация заводында булды. Биредә алар яңартылган Ту-160М ракета йөртүче бомбардировщиклар җитештерү эше белән танышты. Инде хәбәр иткәнебезчә, яңа очкыч 12 гыйнварда тәүге мәртәбә күккә күтәрелде. Ту-160 самолетларын модернизацияләү программасы Россия Президенты Владимир Путин карары буенча тормышка ашырыла. Очкычның тышкы кыяфәте үзгәрмәсә дә, цифрлы технологияләр кулланып, ул өр-яңа технологик базада җитештерелә. Андагы системалар һәм җиһазлар 80 процентка яңартылган. Бу эшне башкару өчен завод цехлары да зур үзгәреш кичерде, хезмәткәрләр өстәмә әзерлек узды.

«КАПО-Композит» предприятиесендә исә Рөстәм Миңнеханов белән Денис Мантуровка МС-21 самолеты өчен детальләр һәм агрегатлар җитештерүне күрсәттеләр. Биредә дә эшне тизрәк башкару һәм чыгымнарны киметү өчен заманча эш алымнары куллана башлаганнар.

2006 елда оештырылган «Химград» технопаркында 360 компания – барлыгы 9,6 мең кеше эшли. 7 предприятиегә чит ил капиталы җәлеп ителгән. Төп юнәлешләр – полимерлар эшкәртү, нано һәм биотехнологияләр, медицина технологияләре, ресурсларны һәм энергияне сак тоту. Узган ел технополиста барлыгы 57,8 миллиард сумлык продукция җитештерелгән. Биредә Рөстәм Миңнеханов белән Денис Мантуров парктагы резидентларының җитештерү мәйданчыклары, продукция үрнәкләре белән танышты.

Казан Кремлендә узган очрашуда Татарстан Президенты белән федераль министр республиканың икътисадын һәм сәнәгатен үстерү турында фикер алыштылар.

СИҢА ДА АВЫР, МИҢА ДА...

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ КАЗАН ХАСТАХАНӘЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕНДӘ БУЛЫП, АНДАГЫ ВАЗГЫЯТЬНЕ КҮЗӘТЕП КАЙТТЫ

Хастаханәләрдә – мәхшәр! Авырып, табибка йомышы төшкән кешеләр бүген шулай дип көрсенә. Мәкерле чир көннән-көн котырган чорда башкача була да алмый кебек. Бүген хастаханәләр ничек яши? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләп, Казан хастаханәләренең берсенә барды.

Күрәчәк булмасын!

Җомга иртәсендә башкаланың Зорге урамында урнашкан 21 нче шәһәр хастаханәсенә юл тотам. Минем белән беррәттән шул ук тарафка бер төркем кеше атлый. Без иң беренчеләрдер дип сөенеп куйган идем, ялгышканмын. Хастаханәдә алма төшәрлек тә урын юк иде инде. Гардеробка кием тапшырганда олы яшьләрдәге бер ханым белән сөйләшеп киттек. Шикәр чиреннән интегүче апа даими күренеп торган табибы белән киңәшләшергә килгән икән. Сүз арасында: «Коронавирус котырган чакта хастаханәгә килергә курыкмыйсызмы?» – дип сорыйм үзеннән. «Беркая чыкмыйча, өйдә яткан күршем дә ковид белән чирләп ята, сеңлем. Күрәчәк булмасын! Бу вирусны йоктырмыйм дип, булган чиреңне дәваламыйча да ята алмыйсың инде», – ди ул.

Хастаханәдә иң күп чиратның кайсы бүлмә янында икәнен чамалыйсыздыр. ПЦР-тест тапшырырга теләүчеләрдән торган сөлге буе чиратта егермеләп кеше санадым. Коронавирус белән авыру сәбәпле «больничный» ачтырырга-озайтырга теләүчеләр сафы да шул чама иде. Чират дигәненең ыгы-зыгылы, гаугалы урын икәнлегенә ияләнеп беткән инде без. Әмма коронавирус бу күренешкә дә төзәтмә керткән, ахры. Һәркем үз чиратын сабыр гына көтеп утыра бирә.

Хастаханә янында яшәүче Алсу Гарипова өч көн элек үзен начар хис итә башлаган. Моңарчы бер дә күзәтелмәгәнчә сәер итеп гәүдәсе сызлаудан туктамагач, даруханәдән экспресс-тест алып караган. Ул уңай нәтиҗә күрсәткән. «Тест чынлап та дөрес нәтиҗә ясаганмы-юкмы икәнен ачыклау өчен ПЦР-тест биреп карарга булдым. Бер дә хәлем юк. Миңа кадәр чиратта 10 кеше бар. Ахыргача көтәм инде. Беркем дә рәхәттән килеп утырмаган, бөтенесе минем хәлдә», – ди Алсу.

Һәркемнән сабырлык сорала

Хастаханәнең баш табиб урынбасары Диана Тимеркаева сүзләренә караганда, бүген хастаханәдә чиратларны булдырмас өчен барысы да эшләнә.

– Чиратларны мөмкин кадәр киметергә тырышабыз. Авыруларны борчыган сорауларга дистанцион рәвештә – телефон аша да җавап бирәбез. Алар да, үз чиратында, безнең хәлгә керсен, вазгыятьне аңлап кабул итсен иде. Коткыга бирелергә ярамый! Чиргә каршы көрәшкәндә иң төп коралларның берсе бу, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Коронавирусның яңа дулкыны эшне аеруча тиз тотты. Диана Тимеркаева сүзләре белән әйтсәк, бер көн эчендә бар дөньяны бөтереп алды ул. «Ашыгыч ярдәм» хезмәтенә шалтыратулар 24 гыйнвардан арта башлаган. «Бу көнне 323 кеше өенә табиб чакыртты. Тормышыбызда коронавирус пәйда булганчы колл-үзәккә көненә шундый 30–40 мөрәҗәгать килә иде. Ковид барлыкка килгәч, табиб чакыручылар саны тәүлегенә 200гә җитте. Моннан да зур саннар була алмый дип уйлаган идек. Ялгышканбыз икән. Кичә, мәсәлән, 375 кеше өенә табиб чакыртты», – ди Диана Тимеркаева. Гомумән алганда, соңгы арада өйгә табиб чакырулар 8–10 тапкыр арткан. Бүген 21 нче шәһәр хастаханәсендә көненә 200ләп кешедә коронавирус ачыклана, 600ләп кешедән мазок алына икән.

Вазгыять катлаулы. Әмма республиканың дәвалау оешмалары коронавирусның яңа дулкынына каршы торырга әзер. «ВТ» хәбәрчесе булып кайткан 21 нче шәһәр хастаханәсен генә алыйк. Биредә коронавирусны дәвалау өчен өстәмә бушлай ташламалы дарулар, вирусны тиз арада ачыкларга ярдәм итүче экспресс-тестлар сатып алынган. Моннан тыш хастаханәгә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен яңа машиналар да тапшырылган. Белгечләр табибларга ярдәмгә ординатор-студентлар җибәргән өчен республиканың медицина юнәлешендә белем бирүче уку йортларына да рәхмәтле.

Диана Тимеркаева сүзләренә караганда, соңгы арада коронавирус белән күбрәк яшьләр авырый башлаган. Бәхеткә, аларның күбесе бу чирне җиңелрәк кичерә. Баш табиб урынбасары моны коронавируска каршы вакцина ясату нәтиҗәсе дип саный.

– Бездә эшләүче табиблар арасында да коронавирус белән авыручылар шактый. Аларның да күбесе – яшьләр. Коронавирус белән авыручы кешене кабул итеп, 2–3 көн узуга, еш кына табиб үзе дә ковид белән авырый башлый. Алар «больничный»га җибәрелә, – ди Диана Тимеркаева.

Билгеле булганча, 2 февральдән хастаханәләрдәге планлы кабул итү, диспансеризацияне туктату турында карар үз көченә керде. Бу коронавирус белән авыручыларга ярдәм итүче табиблар сафын тулыландыру максатыннан эшләнде. Авырып киткән табибларны да нәкъ менә шушы белгечләр алмаштыра. Дөрес, хастаханәләрнең кан әйләнеше системасына кагылышлы авыруларны, шикәр чире, яман шешле авыруларны кабул итүче бүлекләре элеккечә үк эшләвен дәвам итә.

Шул рәвешле болай да алны-ялны белмәгән табибларның эше бүген икеләтә артты. Мондый чакта белгечләрдән генә түгел, алар ярдәм иткән авырулардан да сабырлык сорала. Кирәксә-кирәкмәсә өйгә табиб чакыртмау – мәкерле чир котырганда иң зур ярдәм.

– Әгәр температура 38дән артмаса, өч көн дәвамында ул күтәрелгән очракта да төшеп торса, табиб чакыртырга кирәкми – өйдә генә дәвалану хәерле, – ди Диана Тимеркаева. – Чирнең беренче билгеләре күренүгә үк авыру сәламәт кешеләр янына якын килмәскә, битлектән йөрергә, тиешле даруларны вакытында эчеп, борын, тамакны һәрчак чистартып торырга тиеш. Коронавирусның яңа штаммы, нигездә, өске сулыш юлларын зарарлый. Тавыш карлыгу, тавыш бетү кебек билгеләр дә күзәтелергә мөмкин. Үпкәләр элеккеге штаммнар белән чагыштырганда сирәгрәк зарарлана. Йөкле хатын-кызлар үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга тиеш.

«Татар-информ»

Хөкүмәт йортында Татарстан коронавирус инфекциясенә каршы тору буенча оператив штабның киңәйтелгән утырышы узды. Ул Татарстан Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева җитәкчелегендә үтте. Штаб вәкилләре утырышта вазгыятьне исәпкә алып, яңа карарлар кабул итте. Әйтик, барлык амбулатор дәвалау учрежденияләре шимбә һәм якшәмбе көннәрендә дә эшләячәк. Район башлыкларына, җитәкчеләргә барлык дәвалау учрежденияләрен шәхсән йөреп чыгарга һәм кирәкле ярдәм чараларын күрсәтергә йөкләмә бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӨЙДӘ БОТКА ПЕШМӘСӘ...

Соңгы биш елда Татарстанда балалар һәм үсмерләр арасында симерү очраклары арткан. Бу чирдән тәлинкәдәге ризыкны киметеп кенә котылып булырмы?

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсенең матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, симерү чире белән авыручы 14 яшькәчә балалар саны 27 районда арткан. Мондый хәл бигрәк тә Алабуга, Теләче, Минзәлә, Тукай, Ютазы районнарында күзәтелә. Үсмерләр арасында исә мондый проблема Минзәлә, Питрәч, Яшел Үзән, Чистай, Әгерҗе районнарында бар.

Белгечләр фикеренчә, бу проблеманың килеп чыгуында әти-әниләр дә гаепле. Алар балаларына коры-сары, баллы ризыклар ашата, дөрес тукланугa игътибар бирмиләр. Симерү исә йөрәк-кан тамырлары, скелет-мускул системасының бозылуы, яман шеш авыруларын китереп чыгарырга мөмкин.

Теләче районы хастаханәсенең участок педиатры Рәшидә Исмәгыйлева әйтүенчә, районда 17 яшькә кадәрге 2419 бала исәпләнә. Симерү буенча 14 яшькәчә – 18, үсмерләрдән 9 бала исәптә тора. Мең кешегә 8,8 бала туры килә дигән сүз бу.

– Балалар арасында симерү очраклары күп дип әйтмәс идем. Әмма хәзер бу чир әкренләп авылга да килеп җитте. Элек мондый очраклар юк иде. Аз хәрәкәтләнү, компьютер каршысында озак утыру, дөрес тукланмау, коры-сары ашау менә шундый хәл китереп чыгара. Кечкенәдән өйрәтмәсәң, соңыннан үзгәртү авыр булачак. Өйдә ботка ашарга өйрәтергә кирәк. Мәктәпләрдә бу яктан бердәм меню булдырылган. Теләсә нәрсә алу өчен буфетлар юк. Пешкән ризыклар бирелергә мөмкин анысы. Кайвакыт әти-әниләргә мәктәп ризыгы ошамыйча, үзләре биреп җибәрә. Көне буе ач йөреп, өйгә кайткач, күп итеп ашау да файдага түгел, – ди Рәшидә Исмәгыйлева.

Алабуга районы буенча да вазгыятьне белештек. Монда симерү очраклары буенча төгәл санны әйтә алмадылар.

– Район мәктәпләрендә 9883 бала белем ала. Бердәм меню Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «АБК-Пэймент» операторы тарафыннан төзелгән. Мәктәп ашханәләрендә сосиска, камыр ризыклары бирмибез. Анда туклану дөрес оештырылган. Ашау мәсьәләсен җыелышларда да күтәрәбез. Әти-әниләр арасында төрле караш яши. Балаларга тәмле ризык ашатасылары килә. Әмма ул һәрвакытта да файдалы түгел. Симерү чипсы, шоколад, баллы ризыклар белән мавыгу нәтиҗәсе дип уйлыйм, – ди мәгариф бүлеге белгече Әлфинә Билалова.

Шөкер, симерү чирен белмәүче балалар да бар.

– Безнең авылда 139 бала исәпләнә. Берсе дә симерү буенча исәптә тормый. Пицца, бургерлар авылда сатылмый. Шәһәрдә яннарында гел кафе, әниләренең исә пешерергә вакыты юк. Элек балалар ботка ашаган. Хәзер эше дә юк бит, карны да хәтта трактор көри. Балалар эшләп үсми. Авылда хәрәкәтләнеп торалар анысы. Чипсы, газлы эчемлекләрдән тыелу кирәк, – ди Кукмара районының Купка авылы фельдшеры Гөлзия Нәҗмиева.

Республика мәктәпләрендә 466 меңнән артык бала укый, аларның 97,6 проценты кайнар ризык белән тәэмин ителгән. Шул ук вакытта башлангыч сыйныф укучыларының күбесе көненә ике тапкыр туклана. Узган ел Роспотребнадзор белгечләре кайнар ризык буенча мәктәпләрнең 30 процентын тикшергән. Алдагы уку елы белән чагыштырганда кимчелекләр азрак ачыкланган. Әйтик, былтыр балалар алдына 256 мәртәбә суынган ризык куйсалар, быел 9 очрак кына теркәлгән. Балалар өлешенә кереп, ризыкны аз бирү очраклары да кимегән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсәдуллина әйтүенчә, кайбер уку йортларында коры-сарыны киметкәч, әти-әниләр зарларын белдергән. Яңа СанПиН мәктәпләрдә колбаса кебек ризыкларны ашатуны да тыя. Әмма мәктәп табынында сосискалар һаман да күренә әле.

– Без колбасаның балаларның яраткан ризыгы икәнен беләбез. Шуңа күрә җирле җитештерүчеләр ярдәме белән аны ел ахырына кадәр калдырдык. Ул атнага бер мәртәбәдән дә артыграк бирелми. Лабораторияләрдә тикшерелгәч, продукциянең сыйфаты яхшы дип табылды, – дип белдерде Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина Дәүләт Советында узган утырышта.

Сүз уңаеннан, быел 1 гыйнвардан мәктәп ашханәләрендә эшләүче хезмәткәрләрнең эш хакы уртача 4128 сумга арткан. Узган ел 196 мәктәп ашханәсендә 1 млрд сумлык төзекләндерү эшләре башкарылган. Хәзерге вакытта 2022 елга капиталь ремонтлау программасы проекты әзерләнә, аңа 180 мәктәп кертелгән.

Сәрия МИФТАХОВА

КЕМГӘ – МАННУР АБЫЙ, КЕМГӘ – ШӘЙХИ

Истәлек

Юбилейларга бай гыйнвар аеның нәкъ уртасында аның да туган көне иде. Түгәрәк дата түгел, быел Шәйхи Маннурның тууына 117 ел тулды. Белмәгәннәргә мәгълүмат биреп, белгәннәрнең исенә төшереп үтик әле: Бөек Ватан сугышына киткәнче дә, аннан кайткач та, балалар һәм өлкәннәр өчен күп әсәрләр иҗат иткән зур язучы ул. Үзе исән чакта кырыклап китабы басылып чыккан. Ә ак кирпеч калынлыгындагы «Муса» романын белмәгән, «Агымсуларга карап», «Чын сөю бармы?» дигән повестьларын йотлыгып укымаган кеше сирәктер.



Гадәттә, зур кешеләр турында мәкаләләр зур юбилейлары уңаеннан языла. Мин Шәйхи аганың гап-гади туган көне үтеп киткәннән соң тотындым әле. Чөнки аның Казанда яшәүче 90 яшьлек туганын таптым. Дөресрәге, озак еллар укытучы булып, аннары сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләгән Наилә апа Әхмәтова белән берничә ел таныш идем, аның язучы Маннур абыйсы турында сөйләгәне дә булды.

Наилә апаның әтисе белән туганнан-туган шул «Маннур абый»ның нәкъ менә Шәйхи Маннур икәнен белмәгәнмен. (Туганнары аны Шәйхелислам исеме белән түгел, никтер Маннур дип йөрткәннәр икән.) Гаять зыялы, тугыз дистәсен тутырса да, акылы саф, зиһене ачык бу ханымның язучыга бәйле истәлекләрен сөйләтеп каласым килде.

Билгеле булганча, Шәйхи Маннур элекке Түбән Тәкәнеш (хәзер – Мамадыш) районының Тулбай авылында туган. Наилә апаның әтисе Каюм да – шул авылдан. Ләкин олы кыз Наиләгә 5–6 яшь тирәсе булганда, Каюм абзыйны Балтачка РОНО мөдире итеп билгелиләр дә, гаилә шунда күченә. Бу вакытта Шәйхи Маннур инде Кузбасс шахталарында күмер чабып, Тобол урманнарында комсомол эше белән шөгыльләнеп, Уралда колчедан чыгарып, Минскида армия хезмәтендә булып, Донбасста металл коеп, Мәскәүдә татар газетасы редакциясендә эшләп, Казанга кайткан һәм педагогия институтының тел-әдәбият факультетын тәмамлаган була. Аңарчы да шигырьләр, поэмалар язудан туктамаган, исеме укучылар арасында танылып, әдәби тәнкыйтьтә еш телгә алына башлаган шагыйрьнең Казанда офыклары тагын да киңәеп китә. Боларны Наилә апа башкалар сөйләве буенча гына хәтерли.

– Атаклы «Гайҗан бабай», «Меңнән бер кичә» поэмаларын Маннур абый институтта укыган елларында язган, – дип искә ала ул. – Укып бетергәч, «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә бераз эшләп ала да үзен тулысынча иҗатка багышлый. Бөек Ватан сугышы башланганда, аның Тәгъзимә исемле искиткеч чибәр хатыны, кызы Миләүшә белән улы Илгизәр бар иде. 1942 елда сугышка үзе теләп китә, ахырга кадәр төрле фронт газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Ә китәр алдыннан, туганнар белән бергә булсыннар дип, әти белән киңәшеп, гаиләсен безнең янга кайтарып куйды. Безнең әти инде ул вакытта сугыштан яраланып кайткан иде. Аны яңа оештырылган Чепья районына эшкә җибәрделәр, без шунда күчендек. Тәгъзимә апа, балалары белән Смәел авылына кайтып төште, аны мәктәпкә тарих укытырга билгеләделәр. Алар шунда яшәде. Аннары күпмедер Түнтәр мәктәбендә дә укытты. Аралашып, ярдәмләшеп тордык. Сеңлем анда барып, бала да караште әле. Кечкенә малай озак яшәмәде, чирләп, үлеп китте. Кызлары турында алгарак китеп әйтим инде: Миләүшә, үскәч, кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклап, зур галим булды. Казанда мәдәният институтын оештыручыларның берсе иде. Сугыштан соң Маннур абый гаиләсен киредән Казанга алып китте. Тора-бара аерылышып, икесе ике бүлмәдә яшәсәләр дә, Тәгъзимә апаның бу хакта кешегә сиздерәсе килмәде, күпмедер вакыт Маннур абыйны элеккечә үк карап-тәрбияләп торды. Абый бик ыспай иде безнең, авылга кайткан чакларында да йокыдан торгач, сөлгене кайнар парда тотып, муенына-битенә шуның белән массаж ясый, дип сөйләгән иде әни.

Наилә апаның әтисе пенсия яшенә җитеп килгән елларда алар, тагын күченеп, Түбән Тәкәнешкә кайталар. Каюм абзыйны Түбән Арбаш авылындагы балалар йортына директор итеп куялар. Менә шуннан соң инде язучы абыйлары туган ягына еш кайта башлый. Үзе генә дә түгел әле, күренекле язучы-шагыйрьләрне дә ияртә. Хәсән Туфан, Хәмит Ярми, Гомәр Бәширов һәм башкалар белән мәктәпкә, балалар йортына барып, очрашулар, төрле кичәләр оештыралар.

– Наилә апа, «Муса» романы – зур күләмле әсәр бит, Шәйхи абыйга шактый вакыт кирәк булгандыр аны башкарып чыгар өчен. Сез ул чакны хәтерлисезме? Муса Җәлил белән Шәйхи Маннур бер-берсен белгәннәрме икән? – дип кызыксынам.

– Белү генә түгел, дус булган алар. Романны язарга тотынганчы, ул бик күп материал туплады. Оренбургка, Минзәләгә, Волхов фронты булган җирләргә барды. Хәтта Германиягә үк барып, Мусаның эзләреннән йөреп дигәндәй, ул тоткынлыкта булган төрмәләрне үзе күреп, аны белгән кешеләр белән сөйләшеп кайтты. Романның иң күп өлешен ул Тулбайда, бездә яшәп язды (ул чакта – 1960 нчы еллар башы – без дә шунда күченгән идек). Тулбайда үз акчасына китапханә салдырган иде бит ул. Йөздән артык китап та бүләк итте. (1995 елда бугай, китапханәгә дәүләт музееның филиалы статусы бирелде, ул бина хәзер Шәйхи Маннур исемендәге музей-китапханә дип атала.) Шунда иҗат бүлмәсе бар иде. Иртүк торып, музеена китә дә язып утыра. Өйгә йокларга гына кайта. Романны 1964 елда язып бетерде ул.

– Шәйхи Маннурны замандашлары «әдәбиятыбызның ак йөзе» дип искә алалар. Моның сере нәрсәдә икән? «Иҗатта да, тормышта да кыю кеше иде Шәйхи ага», – диләр. Хәтта, усал иде, диючеләр дә бар.

– Сугыштан соң «Совет әдәбияты» журналында аның бер шигыре басылып чыга. Шуның аркасында булса кирәк, дошман җырын җырлаучы дип гаепләп, Маннур абыйны партиядән чыгаралар. Ә коммунистлар партиясе сафына бит ул фронтта чагында, 1944 елда кабул ителгән була! Әлбәттә, ВКП(б) өлкә комитетының мондый карары белән килешми, Үзәк комитетка кадәр җитсә җитә – гаепсезлеген исбатлауга ирешә. Усал, диюләре шуннандыр: ул ялагайлана белми, ошамаса, турыдан бәреп әйтә торган кеше иде. Язучылар берлегендә җыелышларда, әсәрләр буенча фикер алышканда, аның сикереп торып, авторның йөзенә карап, туп-турысын әйтүе турында үзем дә ишеткәләдем. Тагын шунысы да бар: Татарстанның автономияле республика булуына Маннур абыйның бик тә эче поша иде, аны союздаш итәсе килде. Шактый уйланып, фикерләрен туплап, шул хакта КПСС Үзәк комитетына Никита Хрущев исеменә хат җибәргән. 1957 елда дип исемдә калган. Бу гамәле турында сөйләнеп йөрмәгән, хат язганын беркем дә белмәгән, ахрысы. Сталин үлгәннән соң бик аз вакыт узган бит әле ул чакта, халыкта курку көчле. Аның хаты турында партия җитәкчеләренә хәбәр килми калмагандыр, моның өчен Маннур абыйның башыннан сыйпамаганнардыр, мөгаен. Тик боларны безгә белгертмәде ул. Хатны әле унбиш еллап элек кенә Мәскәү архивыннан тарихчы Әлфия Галләмова тапкан дип беләм.

– Шәйхи аганың алдан ук язып, Илдар Юзеевка биреп куйган васыятьнамәсе булган икән. Сез моны белә идегезме?

– 75 яшен тутыргач, 1980 елның июнендә Казанның бер хастаханәсендә вафат булды ул. Язучыларга да, безгә дә, кызына да авырып ятуын никтер хәбәр итмәгән. Шуңа күрә янына хәл белергә килеп йөрүче дә булмаган. Васыятьнамә турында вафатыннан соң белдек инде. Ул аны бер ел элек үк язып куйган булган. Саклык кенәгәләрендәге барлык акчасын диярлек Тулбайдагы музее файдасына тотарга, Хөршитбану исемле апасына да күпмедер өлеш чыгарырга кушкан. Үзен исә туган авылына алып кайтып җирләргә васыять иткән, урынын да әйткән. Аның исән вакытта ук үз исемендәге премия булдырасы килә иде. Бүләкне балалар өчен язучыларга, шулай ук иң яхшы эшләгән колхозчыларга да бирергә теләде. Язучылар аның васыятен үтәделәр, 1981 елда Татарстан Язучылар берлеге, Мамадыш районының «Чулпан» колхозы һәм Олыяз авыл советы бергәләп Шәйхи Маннур исемендәге премия дә булдырдылар.

Наилә апа сөйләгәннәргә өстәп, шуны да әйтеп үтим инде: Мамадыш шәһәрендә һәм Тулбай авылында күренекле әдип Шәйхи Маннурны искә алу кичәләре быел да үтте, аның исемендәге премияләр дә тапшырылды. Премиягә «Мин дә китәрмен әле» (2019) китабы өчен шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин, «Мои мечты», «Мне снится край любимый» (2020) китаплары өчен шагыйрь Владимир Калашников лаек булды.

Фәния ФӘИЗОВА

ТАТАРНЫҢ ИКЕ БӨЕК УЛЫ

Фәрит Хужин

Шәхесләр

15 февраль көнне герой-шагыйрь Муса Җәлил белән күренекле җырчыбыз Илһам Шакировның туган көне. Мондый тәңгәллек юкка түгелдер дигән уйга килеп, татар халкының бу ике бөек улына битараф булмаган милләттәшләребез социаль челтәрләрдә #җырларым хештегы белән бүгеннән үк акция башлады һәм 15ендә бөтен дөнья буйлап марафон үткәрергә җыендылар. Бу фикерне Татарстан Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татар конгрессы да хуплады.

Социаль челтәрләргә көн саен диярлек Илһам ага җырларын куеп, безнең хәтерләрне яңартучы «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов хәзер бу фикерне беренче булып кем әйткәнен хәтерләп тә бетерми инде. 29 гыйнварда ул, Илһам аганың туган көне уңаеннан акция үткәрик, дигән теләк белән дусларына мөрәҗәгать итә. Теләктәшләр күп табыла. Шунда кемдер Муса Җәлилне дә онытмаска кирәк дигән фикерен җиткерә. Әйткән сүз – аткан ук. Берничә көн элек әлеге мәсьәләне хәл итү өчен оештыру комитеты «Гөлзадә» студиясенә җыелды һәм саллы гына план кабул итте.

– Мондый чаралар беренче чиратта милли байлыгыбызны яшь буынга тапшырып калдыру өчен кирәк. Сер түгел, легендар шәхесләребезне оныта башладык, – дип башлады сүзен Хәлил Гайнетдинов. – Әлбәттә, хәзерге вазгыять катлаулы. Җыелышып, ниндидер чаралар үткәрергә мөмкинлек юк диярлек. Әмма без теләсә нинди эшне онлайн рәвештә башкарып чыга алабыз. Өстәвенә гаиләләрдә, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә Муса Җәлил шигырьләрен өйрәнсәләр, сөйләсәләр, Илһам Шакиров җырларын тыңласалар, кушылып җырласалар, без шактый зур уңышка ирешер идек. Мәсәлән, бакчада Илһам моңы каршы алса, бала барыбер ишетми калмый бит. «Кем җырлый?» – дип кызыксына. Мәктәптә дә шулай. Анда мөмкинлекләр тагын да күбрәк. Бу эшне бүгеннән башлап, 15е көнне дөньяның төрле почмакларында яшәүче татарлар белән марафон үткәреп, нәтиҗә ясар идек. Радиотелевидениеләр, матбугат чаралары белән дә сөйләшүләр булды. Барысы да бу гамәлне бик кирәкле дип тапты.

– Бу татар халкын берләштерә торган көн булсын иде. Безгә бөтен дөнья татарларын күтәреп, милләттәшләребез яши торган барлык почмакларга барып җитәргә кирәк, – дип сүзгә кушылды Гөлзадә Сафиуллина.

Әйтергә кирәк, бу җәһәттән Татар конгрессы үз планнарын корган инде. Акция турындагы хәбәрне татарлар яши торган барлык илләргә дә җибәрергә әзер.

Шулай да оештыру комитетында, беренче чиратта урыннарда эш гөрләп барса, читтәге татарлар белән проблема килеп чыкмас, дигән фикергә килделәр. Димәк, һәр татар кулыннан килгәнне эшләргә тиеш дигән сүз бу. Рөстәм Сәрваров, мәсәлән, үз мөмкинлекләрен җиткерде.

– Муса Җәлилнең шигырьләрен укытып, видеога төшереп, Илһам Шакировның җырлары белән портретын куеп, интернеттагы каналларда таратырга уйлыйм. Моны инде кем тели, барысы да тыңлый алачак, – диде ул. – Бу байлык вакытлыча гына түгел, гомерлеккә шунда кала дигән сүз.

Акция үткәрергә соңга калмадыкмы икән, дигән шикләнүләр дә ишетелде очрашуда. Әмма бу фикерне кире кактылар.

Казан федераль университетында 15 февраль ел саен Муса Җәлил көне буларак үткәрелә икән. Илһам Шакиров турында да онытмыйлар. Конференция уздырганнар. «Илһам Шакиров җырларын таныйсызмы?» дигән бәйге оештырганнар.

– Бу – яшьләрне җыр тыңларга җәлеп итү өчен бик үтемле чара. Муса Җәлил турындагы спектакльне караганнан соң да, Илһам Шакировка багышланган китап чыккач та, зур сөйләшүләр үткәрдек. Тик бездә әле бар нәрсә дә совет чоры кешеләре өчен эшләнә кебек. Яшьләрне җәлеп итү, әләктереп алу бик авыр. Алар кызыксынырлык чаралар уйлап табарга кирәк. Лекция форматын яшьләр кабул итеп бетерми. Шәхесләр, язучылар, галимнәр дә укучылар янына сөйләргә әзерләнеп килсен иде. Яңа чараларны колачлау өчен музыка факультеты белән сөйләшергә кирәк булыр, – диде оештыручылар.

Татар конгрессында да шактый эшләр эшләнә. Дүртенче «Җәлил укулары» конкурсында җиңгән кешеләрнең исемнәре билгеле икән инде. 17 февральдә аларның барысын да Казанга чакырып, зур мәҗлес ясарга җыеналар. «Шагыйрь һәм музыка» дип аталган фестиваль игълан ителгән. Анда музыка мәктәбе, музыка көллиятендә укучылар катнаша. Мондый концертлар Чаллы белән Түбән Камада узган инде. Чираттагысын Милли музейда, Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында, соңыннан Мәскәүдә үткәрергә җыеналар. 15 февральдә көндезге сәгать 12дә Милли музейда Моабит дәфтәренең төп нөсхә көне үтәсен дә хәбәр иттеләр. Муса Җәлил музеена исә Җәлил премиясе лауреатлары җыелачак.

Оештыручылар, әле бик күп нәрсәгә өлгерергә була, республика чаралары янында «Җырларым» акциясе бик урынлы, дигән фикергә килделәр. Тәкъдимнәр дә күп булды. Тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин Тел, сәнгать һәм әдәбият институтында Муса Җәлилнең хатыны Әминә апа тапшырган архив саклануын искәртте. Блогерларны, җитәкчеләрне, рәссамнарны, язучыларны, дин әһелләрен дә изге эшкә тартырга кирәк дигән фикерләр яңгырады.

– Бу зур эшнең башы гына әле, – диде Гөлзадә ханым йомгак ясап. – Онытыла язган бөек шәхесләребез бик күп безнең. Аларның исемнәрен мәңгеләштерергә кирәк. Моны халык үзе генә булдыра ала.

Дөрес әйтә милләтне саклауга үзе дә искиткеч зур өлеш керткән җырчыбыз. Чыннан да, иртән торуга Илһам җырлары белән моңланып алсак, бала-оныкларыбызга Җәлил шигырен өйрәтә башласак, беркем дә комачауламый бит безгә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышын 2022 елның 10 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 3 феврале
№ 1308-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 40361-8 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.
3. 2021 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турында».
5. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 264-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 259-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 265-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
9. «Россия Федерациясе тимер юл транспорты уставы» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 43217-8 номерлы федераль закон проекты хакында («йөрт һәм түлә» шартларында тимер юл транспортында йөртүгә шартнамәләр төзү турында).
10. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.17[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 28683-8 номерлы федераль закон проекты турында (алкоголь продукциясен һәм спиртлы продукцияне сату өлкәсендә административ җаваплылыкны төгәлләштерү хакында).
11. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 41446-8 номерлы федераль закон проекты турында (йорт хайваннарын тоту таләпләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү максатларында).
12. «Көнкүреш билгеләнешендәге пиротехник эшләнмәләрне куллану куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 46601-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 51079-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт оборона заказы буенча продукция бәясе хакында тәкъдим һәм аны җитештерү чыгымнары турында мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында).
14. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 42172-8 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына административ җәза билгеләүне камилләштерү өлешендә).
15. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга чыгымнарны финанслашу өлешендә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең мөрәҗәгате хакында.
16. «Пычраткыч матдәләр калдыкларын квоталау буенча тәҗрибә үткәрү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына атмосфера һавасын пычратуны киметү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 45652-8 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).
17. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 555-8 номерлы федераль закон проекты хакында (алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга шушы продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр чикләрен билгеләү турында хәбәр итү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
18. «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 57343-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт преференцияләре һәм муниципаль преференцияләр бирү максатлары өлешендә).
19. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча тәҗрибә үткәрү турында» Федераль законның 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 43000-8 номерлы федераль закон проекты турында (салым органында һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куелу тәртибен камилләштерү хакында).
20. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179[4] статьясына үзгәрешләр кертү турында» 48712-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын модернизацияләү эшләрен финанслау чыганагы белән тәэмин итү юлы ярдәмендә шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын яңартуны һәм үстерүне кызыксындыру өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 3 феврале
№ 1309-VI ДС



Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ТИЗРӘК! БИЕГРӘК! КӨЧЛЕРӘК!

Бу көннәрдә Пекинда кышкы Олимпия уеннары башланды. Ярышлар хакында кем күбрәк белә икән?

1 Пекиндагы Олимпия уеннарының талисманы – панда. Аның исеме – ...
А) Бин Пон Пон;
Б) По;
В) Бин Дунь Дунь.

2 XXII Кышкы Олимпия уеннары кайда уза?
А) Инсбрук;
Б) Сочи;
В) Канада.

3 Стипль-чез (каршылыклар белән 3000 метр йөгерү) буенча тарихта беренче Олимпия чемпионы булып танылган Татарстан спортчысы.
А) Светлана Дёмина;
Б) Гөлнара Сәмитова-Галкина;
В) Екатерина Гамова.

4 Олимпия уеннарының монда беркайчан да оештырылганы юк.
А) Африка;
Б) АКШ;
В) Россия.

5 Олимпия уеннарына безнең эрага кадәр ... елда Борынгы Грециядә нигез салына.
А) 776;
Б) 766;
В) 394.

6 1900 елда Франциядә уздырылган Олимпия уеннарында җиңүчеләргә медаль урынына нәрсә бүләк иткәннәр?
А) картина;
Б) бәллүр савыт;
В) футболка.

7 Пекинда узган XXIX Олимпия уеннарының шигаре нинди булган?
А) «Килдем, күрдем, җиңдем»;
Б) «Камиллеккә чикләр юк»;
В) «Бер дөнья, бер хыял».

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) Б; 4) А; 5) А; 6) А; 7) В.

Тәмле булсын!

Файдалы коймак

Бу тәмле һәм файдалы рецепт белән үзенең «Инстаграм» сәхифәсендә драматург, журналист Сөмбел Гаффарова бүлеште.

Кирәк булыр:
- Балалар эремчеге – 80–90 г;
- 2 аш кашыгы солы оны (өеп);
- 2 йомырка;
- ярты бал кашыгы камыр көпшәкләндергеч.

Барысын да кушып болгатасы.

Табага атланмай сөртеп, капкач астында кыздырасы.

Балаларыгыз, һичшиксез: «Әни, тәмле булган!» – диячәк.

МӘРЬЯМ САБИРОВА:

«ОЛИМПИЯ ЧЕМПИОНЫ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНАМ»

Алма агачыннан ерак төшми, дигәннәрен раслап торучылар шактый бездә. Данир Сабировның кызлары да – әнә шундый «алма»лар. «Инстаграм» аша күзәтеп барасыздыр: икесе дә сәнгатьтән ерак балалар түгел. Без исә аның олы кызы – яшь гимнастка һәм булачак Олимпия чемпионы Мәрьям САБИРОВА белән сөйләшеп алдык.

:: Гимнастика белән ничә яшьтән бирле шөгыльләнәсең инде?
– Өч яшьтә шөгыльләнә башладым.

:: Гимнастикага йөри башларга кем тәкъдим иткәне исеңдәме?
– Кемнең теләге икәнен бик хәтерләмим инде. Әнием бер тренер янына алып барды. Мин шпагатка утырып карадым да ошаттым. Аннары безнең дәресләр башланды, тартылдык, сузылдык. Һәм... Минем башка анда барасым килмәде. Катлаулы булып тоелган микән соң... Әнием: «Юк инде, син нәрсә. Йөри башладың бит инде, алай ташларга ярамый», – дигәч, каршы килмәдем. Менә шулай тугыз ел йөреп торам инде.

:: Конкурсларда катнашу үзеңә ошыймы?
– Ошый, ләкин мин әле дә каушыйм, борчылам. Хәтта курыккан чакларым да була. Чыгыш ясый башлаганчы, үз-үземне «Мәрьям, син булдырасың!», «Мәрьям, борчылма!» дип тынычландырам. Ә инде күнегүләрне эшли башлау белән, бу дулкынлану үзеннән-үзе юкка чыга.

:: Гимнастикадан тыш, тагын нияр белән шөгыльләнергә яратасың?
– Биергә, бераз гына җырларга, әтием белән видеороликлар төшерергә, гаилә белән театрга, киногa йөрергә яратам.

:: Укырга вакытың каламы соң?
– Вакытны табарга туры килә инде. Мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамларга телим, шуңа күрә тырышам.

:: Мәрьям, әтиеңнең җырларын тыңлыйсыңмы?
– Әйе.

:: Кайсылары аеруча ошый?
– Бөтенесе! Аларның барысы да матур, аерып әйтә торган түгел.

:: Татар җырчыларыннан тагын кемнәрнең җырларын тыңлыйсың?
– Салават Фәтхетдинов, Айдар Галимов, Элвин Грей, Әнвәр Нургалиев, Гүзәл Уразова, Илсөя Бәдретдинова һәм башкалар.

:: Сине еш кына әтиеңнең «Инстаграм»ында да күрәбез. Видеолар төшерергә, гадәттә, кем тәкъдим итә?
– Күбесенчә мин. «ТикТок»ка берәр нинди кызыклы видео төшерү минем идея була. Ә инде безнең халык биюләре белән видеоларны әти уйлап таба.

:: Татар, башкорт халык биюләре турында әйтәсеңдер. Үзеңә ошыймы алар?
– Әйе! Аларны миңа әти өйрәтә. Хәрәкәтләре бик үзенчәлекле һәм, гомумән, бик матур ул биюләр.

:: Сезне өйдә татарча гына сөйләшәләр дип ишеткәнем бар. Дөрес сүзләрме бу?
– Әйе. Ишектән керү белән – булды, бетте, бер рус сүзе чыгарга тиеш түгел. Русча сөйләшә башласак, әти: «Нәрсә? Мин сезне аңламыйм», – дия башлый. Дания дә (Мәрьямнең сеңлесе. – **Ред.**), әнием дә шулай. Үземне хәтерләгәннән бирле әти безгә: «Кызым, син – татар, син үз телеңдә сөйләшергә, аны яхшы белергә тиеш», – дип әйтә.

:: Синең исемең дә шундый матур, Мәрьям!
– Рәхмәт! Әтием кушкан исем, минем үземә дә бик ошый ул. Үземне принцесса кебек хис итәм.

:: Үскәч, кем буласың килә?
– Актриса яисә телевидениедә алып баручы булырга телим. Әтиемә охшыйсым килә.

:: Ә иң зур хыялың нинди?
– Олимпия чемпионы буласым килә.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Киңәш

ДӨРЕС СӨЙЛӘШИК!

Кайбер вакыт балаларга кисәтү сүзләре әйтеп куябыз. Аларның дорфарак яңгыравына игътибар бирмибез дә. Кайбер сүзләрне башкачарак та әйтергә мөмкин икән ләбаса.

Кычкырма! – Тынычрак сөйләш, зинһар!

Егыласың! – Егыла күрмә, үзеңне саклап йөр!

Аннары елыйсы булма! – Ахыры ничек бетәсен уйла!

Әйттем бит мин сиңа! – Башка мондый хаталар ясама, яме!

Бу гамәлең барып чыкмаячак! – Тырышып кара, без сиңа ышанабыз!

Уйнап алабыз

АЮ УРМАНЫНДА

Мәйданчыкның бер очына сызык сызып куела. Бу «урман чите» була. Сызыктан 2–3 адым арырак аю торган урын билгеләнә. Мәйданчыкның каршы ягына «балалар өе» сызып куела.

Бер бала «аю» итеп билгеләнә. Калган уйнаучылар үзләренең өйләрендә урнашалар.

Тәрбияче: «Урманга барабыз», – ди. Балалар гөмбә, җиләк җыйган сыман, бер иелеп, бер тураеп, урманга киләләр һәм әйтәләр:

Аю бабай урманында
Җиләк, гөмбәләр җыям.
Аю өнендә утыра,
Безгә карап үкерә.

Аю бу вакытта үз урынында утырырга тиеш. Балалар «үкерә» дигән сүзне әйтүгә, аю, үкереп, урыныннан тора, ә балалар өйгә йөгерәләр. Аю аларны тотарга (әбәкләргә) тырыша. Тотылган баланы аю үз өненә алып китә. Балалар яңадан җиләк һәм гөмбә җыя башлыйлар.

Аю 2–3 уйнаучыны тоткач, яңа аю сайлана, һәм уен яңадан кабатлана.

Башыңны эшләт!



Хикәя

Блогер

Марат блогер булачак! Ул бүген шулай хәл итте. Ничек алданрак башына килмәгән?! Иң җиңел, иң кызыклы һөнәр ич бу. Җитмәсә, иң «текә» һөнәр. Әнә ул мөкиббән киткән блогерларның миллионлаган язылучылары бар. Менә бу популярлык ичмаса... Марат сәгатьләр буе карый аларның блогын. Диванга кырын ятып, авызын ябарга да онытып карый. Шуларны карый-карый, кайбер көнне өй эшләрен эшләргә дә вакыт калмый. Урамга да чыгылмый, бүлмә дә җыештырылмый, ашарга да онытыла хәтта. Әкәмәт инде. Менә тиздән аның үзенә дә «зәңгәр экран»нардан миллионлаган мөкиббән күз төбәләчәк. Бу уйлардан Марат 10–15 сантиметрга үсеп киткәндәй булды, тураебрак утырды хәтта.

Булачак блогер мәктәптән кайтып керешкә үк эшкә тотынды. Портфелен бер якка, курткасын икенче якка атты да телефонына ябышты. Берәр бик шәп видео төшерергә кирәк тиз генә. Тә-ә-әк... Караучылар күп булсын өчен, кызыклы һәм файдалы булырга тиеш бит инде ул. Башта спорт белән шөгыльләнгәнен төшерергә уйлады малай. Спорт файдалы ич. Супер физзарядка күрсәтсен әле менә. Әмма турникта көч-хәл белән ике тапкыр тартылып төшкәннән соң, бу фикернең бик үк уңышлы түгеллеген аңлап алды.

Әһә, менә соңгы арада математикадан тапкырлау таблицасын ятлатып теңкәгә тияләр. Нигә әле шуны өйрәтеп, видео төшермәскә. Вәт баш! Һәм малай бөтен аң-белемен җигеп, эшкә кереште. «Җидене сигезгә тапкырласаң, кырык җиде була ул, дуслар. Биш дүртең – егерме биш. Ә алтыны дүрткә тапкырласак, егерме алты килеп чыгачагын төнлә уятып сорасалар да беләм мин!..»

Марат икенче көнне «йолдыз» булып балкып уянды. Кая, «Марат Сол» («Марат Солтанов» дисәң, текә түгел ич!) каналына ничә мең кеше язылды икән, дип кәефле генә экранны кабызып җибәрсә... Бер язылучы! Математика укытучысы Зөлфия Камилевна! «Марат, иртәгә тапкырлау таблицасын яттан сөйләргә әзерлән. Видеоңның ссылкасын әти-әниеңә дә җибәрдем...» – дип комментарий да калдырган җитмәсә. Менә сиңа популярлык... Блогер булу өчен дә яхшы укырга кирәк шул. Һәм тапкырлау таблицасын белергә!

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

pixabay.com

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 217

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+